*Нурмөхәммәтова Р. С. (КФУ, Казан)*

# ТАТАР ТЕЛЕ ЛЕКСИКАСЫНЫҢ ФОРМАЛАШУ ТАРИХЫН ӨЙРӘНҮ ЧЫГАНАГЫ БУЛАРАК ТАТАРЧА-РУСЧА СҮЗЛЕКЛӘР (ХХ ГАСЫРНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЯРТЫСЫ)

**Аннотация:** Первая половина XX века – важнейший этап в истории России, эпоха больших общественно-экономических перемен, время перестройки народного хозяйства. Период 1900-1950 годов – весьма ответвенный и богатый испытаниям период и для татарского народа. С политической точки зрения, это – время революций, коллективизации, культа личности, годы Великой Отечественной войны... Изменения, происходящие в лексике литературного языка открыто отражают все эти события. А лексические изменения тех далеких времен зафиксированы в словарях татарского языка.

**Ключевые слова:** татарский язык, лексика, татарско-русские словари, первая половина XX века.

## Tatar-Russian dictionaries as sources for the study of the history of the formation of the vocabulary of the Tatar language (the first half of the twentieth century)

**Abstract:** The first half of the 20th century is important point of Russian history, period of socio-economic changes and time of national economy changing. 1900-1950 years are important

period especially for Tatar nation which is full of trials. As for social life, it's time of revolutions, collectivization, personality cult, Great Patriotic War. These events affected vocabulary of tatar language. We can see this influence in material of dictionaries.

**Key words:** Tatar language, vocabulary, the Tatar-Russian dictionaries, the first half of the twentieth century.

Телнең үсеше һәм үзгәреше иҗтимагый-тарихи шартлар һәм бер-берсенә тәэсир итүче телләрнең үзенчәлеге белән билгеләнә. Телнең үсеше – аның сүзлек составы баю, сүзләрнең билгеле бер төшенчәләрне белдерү өчен ныгуы, аның грамматик системасы камилләшү дигән сүз [3, с. 19 и 25].

Телнең үсеше турында сөйләгәндә, лексикадагы үзгәрешләргә күбрәк игътибар итәләр. Беренче карашка телнең үсешен аның лексик материалы нигезендә күзәтү барыннан да җиңел кебек. Лексика өлкәсендә тел, чыннан да, хәрәкәтчәнрәк. Кешелекнең матди һәм рухи тормышы теләсә кайсы телнең сүзлек составында чагылыш таба. Бер төркем сүзләр үткәндә кала, искерә яки бөтенләй онытыла, икенчеләре исә, киресенчә, яңадан ясала, телне баета, аның кулланылыш чикләрен киңәйтә [1, с. 41].

Лексика, ягъни телнең лексик фонды, бердәм тел системасының состав өлеше буларак, аның калган якларыннан – фонетика, морфология, синтаксистан кискен аерыла. Бу аерымлык аның турыдан-туры чынбарлыкка йөз тотуыннан гыйбарәт. Шуңа күрә җәмгыять тормышындагы барлык үзгәрешләр, барыннан да элек лексикада күренә [2, с. 75].

Хәзерге татар теле лексикасын бай һәм киң этрафлы сүзләр системасы һәм аларның мәгънәләре тәшкил итә. Аның лексик байлыгы зур үсеш алган телләрдән берничек тә калышмый. Анда төрле структураларга һәм стильләргә караган йөзләрчә мең сүзләр бар.

Татар теленең лексик байлыгы акрынлап формалашкан. Еллар үтү белән яңа сүзләр барлыкка килгән, яшәп килгән сүзләрнең мәгънәләре киңәйгән. Бу процесс халыкның сәяси, икътисади һәм мәдәни тормышы белән бәйләнештә барган [6, б. 204].

Әдәби телнең формалашу процессы – идарә итеп булмый торган күренеш. Телгә аңлы рәвештә тәэсир итәргә тырышуларның ахырына кадәр һәм тулысынча тормышка ашырыла алмауларын тарих тулысынча исбатла-

ды. Язу традициясе көчлерәк булган саен, әдәби тел белән «җитәкчелек итү» авыррак була. Сүзлекләр һәм грамматикалар исә телдә табигый рәвештә бара торган һәм җитди үзгәрешләрне чагылдыралар [4, с. 143].

Сүзлекләр татар теленең бердәм лексик нормалары эшләнүенең озын һәм дәвамлы процессын ачык күрсәтәләр. Татар әдәби теленең төп лексикасын, билгеле бер күләмдә архаизмнар, тарихи сүзләр, терминнар һәм лексик диалектизмнарны җыйнап биргән хәлдә, алар татар тел белеменә дә кыйммәтле өлеш кертәләр. Әлеге хезмәтләр татар теле лексикасын фәнни яктан өйрәнү өчен ышанычлы чыганак булып торалар.

XX гасырның беренче яртысы җәмгыятьтә барган зур үзгәрешләр белән характерлана. Әлеге дәвер татар лексикографиясе тарихында да әһәмияткә ия. Бу чорда XIX гасырда тупланган тәҗрибәне кабул итеп, аны лаеклы дәвам итү лексикография алдына куелган иң төп максат була. 1900-1950 елларда татарча-русча сигез сүзлек басылып чыга: М.Юнысов сүзлекләре (Казан, 1900, 1906), С.-М. Ганиев сүзлеге (Баку, 1904), Н.Ф.Катанов (Казан, 1912), С.Рахманколый (Казан, 1913), И.П.Березгин (Уральск, 1914) һәм авторлар коллективы тарафыннан төзелеп, Казанда басылган 1927, 1931, 1950 нче елгы сүзлекләр [5, с. 8-13]. Халык хуҗалыгының төрле өлкәләрендәге, сәясәттәге, икътисадтагы һ.б. күп төрле яңалыклар телнең сүзлек составын даими үзгәртеп, тулыландырып һәм яңартып торалар. Сүзлекләр, җәмгыятьнең көзгесе буларак, шул үсеш-үзгәрешләрне объектив рәвештә теркәп барганнар.

XX гасырның беренче яртысы – татар халкы өчен аеруча җаваплы, сынауларга бай чор. Татар теле тарихында XX гасырның беренче яртысы бары тик билгеле бер дәрәҗәдә генә шартлы «чик»не тәшкил итә: гасырлар һәм аларның аерым өлешләре белән билгеләнә торган тел үсеше «чор»ларының шартлы булуыннан чыгып караганда, ул тарихи яктан ачыграк күренеп тора. Сәяси яктан, бу – революцияләр дәвере, колхозлашу чоры, шәхес культы, Бөек Ватан сугышы еллары... 1900-1950 нче еллар – Россия тарихында әһәмиятле этап, зур иҗтимагый– икътисади үзгәрешләр дәвере, халык хуҗалыгын үзгәртеп кору вакыты. икътисади һәм иҗтимагый процессларга китерүче сәяси вакыйгалар бу чорда күп санлы һәм киң колачлы. Әдәби телнең сүзлек составында барган үзгәрешләр бу күренешләрне ачык чагыл-

дыра. Аларны исә без нәкъ менә сүзлекләр материалыннан ачык күрәбез.

Кешелек тарихында беренче социалистик дәүләт барлыкка килү һәм үсә башлау татар теле лексикасының да алга таба кызу темплар белән яңару һәм үзгәрүенә сәбәп була. Яңа матди, иҗтимагый һәм рухи тормыш шартларында татар теленең сүзлек составы да күзгә күренеп үсә башлый. Аның сүзлек байлыгы, тормышның төрле өлкәләрендә барган яңа күренешләр кебек үк, сизелерлек арта: иҗтимагый-сәяси, икътисади, фәнни, техник һәм көнкүрештәге яңа күренешләр яңа атамалар таләп итә. Татар теле лексикасының бу чордагы үсешен билгеләүче төп тенденция – барлык гамәлдә булган лексик чараларны, нинди чыганактан булуларына карамастан, берләштерүдән гыйбарәт. Татарча-русча сүзлекләрдә бу тенденция нәтиҗәләре аеруча ачык һәм тулы чагылыш таба.

Тикшерелә торган чор, алда санап үтелгән үзгәрешләрдән тыш та, татар халкы тормышында аеруча тирән эз калдырган вакыйгаларга бай була: бу елларда татарлар өч тапкыр язу алыштыралар. Иң элек татар теленә бик үк яраклаштырылмаган гарәп язуы кулланыла (бу чор 1913 елгы сүзлектә чагылыш таба). 20 нче еллар башында гарәп язуын татар теленә яраклаштыру мәсьәләсе кузгатыла. Гарәп язуына кайбер үзгәрешләр кертелгәннән соң, 1927 елгы сүзлек дөнья күрә, анда хәтта гарәп сүзләре дә фонетик принцип белән бирелә. Латин язуына күчүгә, 1931 елгы сүзлек басыла. Кириллица нигезендә төзелгән татарча-русча сүзлек Бөек Ватан сугышы, аннан соңгы хуҗалыкны торгызу еллары мәшәкате белән озак чыга алмый тора, ул бары 1950 елда гына пәйда була. Бу вакыйгалар телнең лексикасы үсешенә дә йогынты ясамый калмаганнар.

Тикшерелгән татарча-русча сүзлекләр төрле авторлар тарафыннан, хәтта төрле төбәкләрдә дә басылганнар. Аларны лексикографик тәҗрибәсе зур булган авторлар төзегәне күренеп тора. Бу хезмәтләрнең төп максаты – татар сүзләренең русчага төгәл һәм дөрес тәрҗемәләрен бирү. Аларда бай фразеология, татар халкының тарихына, гореф-гадәтләренә, мәдәниятенә һ.б. өлкәләргә караган төшенчәләр теркәлгән. Һәр сүзлек, күләме мөмкинлек биргән кадәр, үз чорындагы татар теленең актив сүзләрен туплаган.

Сүзлекләрнең лөгатьлекләре бердәй түгел һәм алар сүзләрнең саны белән дә берберсенә туры килми. Сүзләр саны ягыннан лөгатьлекләр

якынча 3 меңнән 20 меңгә кадәр берәмлекне тәшкил итә. Һәр сүзлек алдагыларыннан лексик материалның күләме белән генә түгел, бәлки сүзлек мәкаләләренең тулылыгы һәм яңача эшләнеше белән дә аерылып тора.

Гасыр башында төзелгән сүзлекләр теркәлгән сүзләренең азрак, тәрҗемәләрнең берьяклырак булуы белән дә үзенчәлекле. XX гасыр урталарына таба гомумхалык мәнфәгатьләренә җавап бирердәй, киң катлау укучылар өчен төзелгән сүзлекләр басыла башлый. Элегрәк чыккан сүзлекләр татар теле сүзләрен русчага тәрҗемә итүне генә күздә тотса, соңрак чыккан сүзлекләр грамматик белешмә вазифаларын да өлешчә үз өсләренә алалар.

Сүзлекләрнең төзелү принциплары хәзерге замандагы сүзлек төзү принципларына якын тора. Нинди генә графика кулланылмасын, сүзләр алфавит тәртибендә урнаштырыла, күпчелек сүзлекләрдә бу тәртип сүзнең беренче хәрефенә генә түгел, аннан соң килгәннәренә дә карый. Татарча-русча сүзлекләр тел фактларын туплау, аларны лексикографик эшкәртү җәһәтеннән елдан-ел камилләшә барганнар.

Ике телле сүзлекләрдә, нигездә, туры (эквивалент) тәрҗемә төп урынны алып тора. Тәрҗемә ителә торган сүзләрнең мәгънәләренә тәңгәл килә торган сүзләр эзләгәндә, авторлар рус теленең синонимик байлыгыннан да киң файдаланганнар, шул рәвешчә тасвирлама тәрҗемәләрдән котылу юлын тапканнар.

Әлеге сүзлекләрдә сүзләрнең барлык мәгънәләрен дә ачу максат итеп куелмаган. Авторлар, нигездә, сүзләрнең ул чорда аеруча актив йөргән мәгънәләрен генә теркәгәннәр. Бу, әлбәттә, сүзлекнең гамәли максатлардан чыгып төзелүенә дә бәйле булырга мөмкин. Шуңа карамастан, кайбер сүзлекләрдә полисемиягә дә игътибар ителгән: XX гасыр урталарына таба чыккан сүзлекләрдә күпмәгънәле сүзләр аеруча ачык чагылыш тапкан.

XX гасырның беренче яртысында чыккан сүзлекләрдә, бүгенге тел күзлегеннән чыгып караганда, архаизм дип саналган берәмлекләр дә, диалекталь сүзләр дә шактый. Бу – табигый күренеш, чөнки сүзлекләр теге яки бу чордагы телнең яшәешен, телдәге хәрәкәтне, үсеш тенденцияләрен беркетеп калалар.

Төрле сүз төркемнәренең бирелешенә бәйле үзенчәлекләргә килгәндә, Октябрь борылышына кадәр чыккан сүзлекләрдә фигыльләр -мак/-мәк формасында теркәлгәннәр. Октябрь боры-

лышыннан соң фигыльләр нигез формасы белән дә, исем фигыль кушымчасы белән дә бирелгәннәр. Исемнәр барлык сүзлекләрдә дә баш килештә урын алган. Сыйфатларның кайбер дәрәҗәләре һәр сүзлектә дә очрый. Ярдәмлек сүзләр төрле сүзлектә төрлечә чагылыш тапкан.

Татарча-русча сүзлекләрдә, гадәттә, билгеле бер чорның аралашуда иң кирәкле сүзләре урын ала. Алардан тикшерелә торган дәвердә төрки-татар нигезләреннән төрле кушымчалар ярдәмендә исемнәр, сыйфатлар һәм фигыльләр ясалуын күрергә мөмкин. Синтаксик юл белән сүзләр ясау да активлаша. Бу чорда абстракт мәгънәле сүзләр, төрле корал-җайланмаларны атаучы берәмлекләргә ихтыяҗ зур булганлыктан, шундый эчтәлектәге исемнәр күпләп ясалган.

Бу чорда шулай ук татар теленең үз чараларын кулланып, рус сүзләре үрнәгендә сүз ясау да (калькалаштыру) бик киң тарала.

Татар теленең лексик составы үсешендә сүзьясалышы һәм диалектларның гына түгел, ә телдә моңа кадәр кулланылышта булган берәмлекләрнең мәгънә эчтәлеге киңәю яки тараю да үз ролен уйнаган. Бу юл белән дә телнең лексикасында үзгәрешләр барлыкка килгән.

Башка телләр белән төрле бәйләнешләргә керү туган тел язмышында, аның һәр тарихи үсеш дәверендә хәлиткеч эз калдыра. Бу – телнең лексик составы артуда бәхәссез чыганакларның берсе. Тикшерелә торган чорда татар теле чит телнең әзер лексемалары хисабына да баеган. XX гасырның беренче яртысындагы татар телендә ике төрдәге алынмалар зур урын тота: гарәп-фарсы сүзләре һәм рус-европа алынмалары. Әмма бу ике төр алынмаларның тоткан урыны ярты гасыр дәвамында үзгәрә бара: гасыр башында алынмалар арасында гарәп-фарсы сүзләре зур күпчелекне тәшкил иткән булып (2000 нән артык берәмлек), рус сүзләре бик аз теркәлсә (сүзлекнең 0,7 % ы); 30 нчы елларда алар сан ягыннан бер дәрәҗәдә, хәтта аерым берәмлекләр үзара синонимнар булып та йөриләр. 40 нчы еллар лексикасында исә гарәп-фарсы алынмаларының бик нык үзләшкәннәре генә кала, ә зур күпчелек исә искергән сүзләр рәтенә күчә, аларны татар теленең үз чаралары белән ясалган сүзләр яисә рус-европа сүзләре алыштыра.

XX гасырның беренче яртысында гамәлдә булган гарәп-фарсы алынмалары күбрәк зат, аның тышкы һәм эчке халәте, табигать күренешләре, дини ышанулар, тормыш-көнкүреш, мәгариф

белән бәйле сүзләр булса, рус-европа сүзләре җәмгыять тормышындагы кискен үзгәрешләр белән бергә килеп керә, шунлыктан алар иҗтимагый-сәяси, икътисади, фән-техника һ.б. өлкәләрдә туган яңа күренешләрне атыйлар. Алынмалар арасында, гадәттә, абстракт төшенчәләрне белдерүче берәмлекләр күп була, әмма яңа предметлар белән бергә конкрет мәгънәле сүзләр дә күпләп үтеп керә. Гарәп-фарсы сүзләренең татар теленә үтеп керүе тикшерелә торган чордан күп элек башланган, шунлыктан алардан татар теле чаралары белән яңа сүзләр дә күп ясалу табигый. Рус-европа берәмлекләре дә татар телендә чагыштырмача тиз үзләшеп китәләр, 30-40 нчы елларда инде алар да телнең сүзьясалыш процессында катнаша башлыйлар.

Шул рәвешчә, лексикографик чыганаклар татар әдәби теле лексикасының формалашуын фәнни яктан өйрәнү өчен ышанычлы материал бирәләр һәм яңа, тагы да камилләшкәнрәк татарча-русча сүзлекләр төзү өчен ныклы нигез булып торалар.

Әдәбият:


1. Будагов Р.А. Язык, история и современность. М.: Изд-во Моск. ун-та, 1971. 300 с.

2. Валгина Н.С. Активные процессы в современном русском языке. Учебное пособие. М.: Логос, 2001. 303 с.

3. Закиев М.З. Некоторые вопросы развития татарского литературного языка // Вопросы татарского языкознания. Казань: Таткнигоиздат., 1965. С. 5-37.

4. Мечковская Н.Б. Социальная лингвистика. М.: Аспект Пресс, 1996. 206 с.

5. Нурмухаметова Р.С. Основные тенденции развития лексики татарского литературного языка первой половины XX века (па татарско-русским словарям). Автореф. дисс….канд.филол. наук. Казань, 2005. 26 с.

6. Татар грамматикасы: Өч томда. М.: Фикер, Казан: Иман, 1998. Т. 1. 511 б.